ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлегенең Яхшы-Каран торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

17 ноябрь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елнын 06 октябрендәгы № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлегенең Яхшы-Каран авылында гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Яхшы-Каран авылы территориясендә теркәлгән инвалидлардан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшькә җиткәннәр) һәм көндезге уку формасы буенча укучы, хәрби хезмәт, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәтләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Яхшы-Каран т.п. урамнарында яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы (лампа, энергияне сак тоту яктырткычлары, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

2) Яхшы-Каран авылында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3)Яхши-Каран авылында һәйкәлләрне ремонтлау һәм аның янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерү ( Боек Ватан сугышында катнашучылар исемлеге белән истәлек тактасы урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

4) Яхши-Каран авылы, Мифтахова, Родниковая урамнарында эчке эшләр ремонтлау, урам юлларына вак таш җәю.

5) Яхши-Каран авылында Өлкәннәр көнен үткәрү өчен бүләкләр сатып алу.

3. Әлеге карарны Александровка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында ( http:// sarmanovo. tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге башлыгы
гражданнар җыенында рәислек итүче И.Ф.Вафин